| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |
|---|---|

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

5 июль 2018ел № 3-34

Буа шәһәре Советының 2016 елның 18 октябрендәге
1-12 номерлы «Җир салымы турында» карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пункты, 56 статьясы нигезендә Буа шәһәр Советы карар кабул итте:

1. Буа шәһәре Советының 2016 елның 18 октябрендәге 1-12 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 4 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җир салымын түләүдән азат итәргә:

1.1. Гражданны күмүләр белән мәшгуль җир кишәрлекләренә карата оешмалар, учреждениеләр, Россия Федерациясе Салым кодексының 389 статьясында каралган очраклардан тыш.

1.2. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, казна учреждениеләре, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетыннан гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата финанслана торган бюджет һәм автоном учреждениеләр (парклар, скверлар, шоссе, урамнар, тыкрыклар, юл йөрү, мәйданнар һәм гомуми файдаланудагы башка җир кишәрлекләре)».

2. Әлеге карарның гамәлдә булу көче 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

ТР Буа муниципаль районының Буа шәһәре башлыгы М.А.Җаббаров